

5-8 февраль коннәрендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырылган татар теле һәм әдәбиятыннан тобәкара олимпиада vтте. Олимпиадада Россиянен 22 тобәгеннән 8, 9, 10, 11 сыйныф укучылары катнашты, шул исәптән Мордовиябезнен дvрт укучысы; алар – призерлар.  Чара Россия Федерациясе тобәклә-ренен мәгариф идарәсе органнары белән тозелгән белем бирv олкәсендә хезмәттәшлек турында килешvләрне гамәлгә ашыру, туган (татар) телнен дәрәжәсен һәм укучыларнын белем дәрәжәсен кvтәрv, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына гамәли ярдәм кvрсәтv максатыннан уздырыла.
Олимпиаданын ябылыш тантанасы 2024 нче елнын 7 нче февралендә К.Тинчурин исемендәге Татар дәvләт драма һәм комедия театрында vтте. Чарада Ботендонья татар конгрессы Башкарма комитеты житәкчесе Данис Шакиров катнашты. Зур максатлар белән чираттагы сынау кинлегенә чыккан укучыларыбыз быел Саранск башкалабызда узган республика олимпиадасы жинvчеләре иде. Алар остазларынын ышанычын акладылар, белем тирәнлеге белән соендерделәр. Газиз ана телен яхшы белvче кызлар беренче конне татар теле һәм әдәбиятыннан тирән белем байлыгын танытса, олимпиаданын икенче конендә “Гаилә елы”на багышланган ижади бәйгедә сәнгатьле сойләм осталыгын кvрсәттеләр. Шул арада укытучылар очен дә торле очрашулар vтте. Олимпиада кысаларында катнашучылар очен Казаннын истәлекле урыннары белән танышуны vз эченә алган мәдәни-экскурсион программа, Г.Камал һәм К.Тинчурин театр-ларында спектакльләр карау каралган иде. Укучыларыбыз башка регион яшьтәшләре белән дуслаштылар, татар телендә аралаштылар. Без бу чарада катнашуыбызга бик шат, татар телебез һәм әдәбиятыбыз тобәкара олимпиадасында катнашуыбыз белән бәхетле мизгелләр кичердек.
Мордовиядән Кильдеева Зәйнәб Хосәен кызы житәкчелегендә татар теле буенча Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбенен 9 сыйныф укучысы Салькаева Сафина (укытучысы – Альфия Фатих кызы Муртазина), шул ук районнын Пензятка урта мәктәбе 10 сыйныф укучысы Бикмурзина Зухра (укытучысы – Равза Мукаддяс кызы Юмаева) белем ярышында катнаштылар. Татар әдәбияты олимпиадасында Кадошкино районы Большие Поляны топ мәктәбе 9 сыйныф укучысы Кильдеева Дарина (укытучысы - Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева) белән Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбенен 9 сыйныф укучысы Мусалеева Юлия (укытучысы – Фазия Фәрит кызы Боярова) белемнәре буенча ярыштылар. Алар барысы да тобәкара татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиада призерлары. Призерлар әзерләгән укытучылар Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы Грамоталары белән бvләкләнделәр.
Укучыларыбызны олы унышлары белән ихластан котлыйм! Аларнын Казанда да сынатмый, югары нә-тижәләргә ирешvе остазларынын, укучыларынын һәм аларнын гаилә-ләренен кvпъеллык хезмәтен, тырышлыгын раслый. Бу зур куанычлы вакыйга! Үз чиратында укучыларыбыз туган телләре белән горурланып яшәрләр, бервакытта да онытмыячакларлар, балаларына да ойрәтәчәкләр дип уйлыйм. Бу чарадан алган эмоцияләрен гомерләре буенча сагынып сойләрләр. Олы рәхмәтемне ягымлы, итагатьле балалар тәрбияләгән әти-әниләренә, ныклы белем һәм телебезне яратырга ойрәткән

укытучыларына, Тобәкара олимпиадасын оештыручыларга белдерәсем килә. Нәкъ Гаилә елында мәктәпнен һәм гаиләнен бердәмлеге бик тә моһим.
Олимпиада программасы белән каралган чаралардан тыш, укучыларыбыз Казан кирмәне, Кол Шәриф мәчете, Соембикә манарасын китаптан гына тvгел, ә vз кvзләре белән кvрделәр; Муса Жәлил һәйкәле янында булдык, Бауман урамы буйлап сәяхәт кылдык. Болар барысы да кvнелләрендә озакка сакланып калыр.
Кадерле яшь дуслар, сезнен максатчанлык, унышлар ботен республикабыз мәктәпләрендә белем алучы яшьтәшләрегезгә, укучы малай-кызларга vрнәк булсын. Сезнен сафларга кушылучылар кvп булсын!

**Зәйнәб КИЛЬДЕЕВА**